СОВЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ с.Старое Дрожжаное **КАРАР**

2025 елның 15 декабре № 4/5

«Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының даими нигездә муниципаль вазыйфаны биләүче затларга, контроль-хисап органы рәисенә акчалата бүләкләүләр, муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады күләмнәрен, айлык һәм башка өстәмә түләүләрен һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында» 2018 елның 30 мартындагы 26/1 номерлы Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 елның 25 ноябрендәге 994 номерлы «Татарстан Республикасында даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарә органнарының сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, рәис урынбасарларының, аудиторларының, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт хакын түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» карары, Чүпрәле муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советының 2018 елның 30 мартындагы 26/1 (11.05.2018 № 27/3, 28.09.2020 № 1/5, 03.02.2022 № 16/1, 10.11.2022 № 22/3, 14.12.2022 № 23/9, 13.02.2023 № 25/3, 29.05.2024 № 38/6, 08.11.2024 № 40/6, 22.05.2025 № 46/2 редакциясендә) номерлы «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының даими нигездә муниципаль вазыйфаны биләүче затларга, контроль-хисап органы рәисенә акчалата бүләкләүләр, муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады күләмнәрен, айлык һәм башка өстәмә түләүләрен һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) **1 пунктта** «15 389» санын «16 928,0» санына алмаштырырга;

2) **1 нче Кушымтаның таблицасын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«МУНИЦИПАЛЬ ВАЗЫЙФАЛАРНЫ ДАИМИ НИГЕЗДӘ БИЛӘҮЧЕ ЗАТЛАРГА, МУНИЦИПАЛЬ РАЙОННЫҢ КОНТРОЛЬ ХИСАП ОРГАНЫ РӘИСЕНӘ ХЕЗМӘТ ХАКЫ КҮЛӘМЕ ҺӘМ ШАРТЛАРЫ

Вазыйфаның атамасы	Акчалата бүләкләү күләмнәре (сумнарда)		
	8 төркем	10 төркем	12 төркем
Муниципаль район Башлыгы	44 814,00		
Чүпрәле муниципаль районы Башлыгы урынбасары	40 334,00		
Контроль-хисап органы рәисе	40 334,00		
Авыл җирлеге башлыгы урынбасары		20 565,00	
Авыл җирлеге башлыгы			23 201,00».

3) **2 нче Кушымтаның таблицасын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МУНИЦИПАЛЬ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРЕНЕҢ ВАЗЫЙФАИ ОКЛАДЛАРЫ КҮЛӘМЕ

Вазыйфаның атамасы	Вазыйфаи эш хакы
1	2
Башкарма комитет Җитәкчесе	44 014,00
Район Советы аппараты Җитәкчесе	39 951,00
Район Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары	39 613,00
Башка җирле үзидарә органы җитәкчесе	39 443,00
Эшләр идарәчесе	37 073,00
Башка җирле үзидарә органы җитәкчесе урынбасары	36 226,00
Бүлек начальнигы	30 809,00
Район Башлыгы киңәшчесе	26 916,00
Район Башлыгы ярдәмчесе	26 916,00
Район Башкарма комитеты Җитәкчесе ярдәмчесе	26 916,00
Бүлек башлыгы урынбасары	26 916,00
Сектор мөдире	24 885,00
Баш белгеч	23 869,00
Әйдәп баручы белгеч	22 176,00
1 категорияле белгеч, 2 категорияле белгеч, белгеч	20 314,00»;

4) **3 нче Кушымтаның таблицасын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АВЫЛ ҖИРЛЕКЛӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРЕНЕҢ ВАЗЫЙФАИ ОКЛАДЛАРЫ КҮЛӘМЕ

	Вазыйфаларның исеме	Хезмәт хакы	
		10 төркем	12 төркем
1.	Башкарма комитет Җитәкчесе	27 593,00	
2.	Башкарма комитет секретаре		22 515,00».

2. Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыгарга тиеш.

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башлыгы, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы Рәисе М.Р. Гафаров